ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.07.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1696**

Зеленодольск муниципаль районында «Миллион чәчәк шәһәре-2021» проекты кысаларында конкурслар үткәрү турындагы нигезләмәне раслау турында

Зеленодольск муниципаль районы халкы һәм учреждениеләре арасында «Миллион чәчәк шәһәре» төзекләндерү һәм яшелләндерү проектын тормышка ашыру максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Минем миллион чәчәк - 2021» (Зеленодольск шәһәре), «Чәчәк ат, Васильево-2021» (Васильево штп) « Чәчәк ат, Осиново-2021» (Осиново авыл җирлеге) «Чәчәкле ишегалды - 2021» (Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләре) конкурсларын үткәрү турындагы нигезләмәне әлеге карарга 1 нче кушымта буенча расларга.
2. 7 нче кушымта буенча комиссия составын расларга.
3. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе 2-5 нче кушымталарга ярашлы рәвештә, конкурсларның приз фондын 860 000 сум күләмендә, шулай ук 6 нчы кушымта нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджетында әлеге максатларга каралган акчалар хисабына, конкурсны үткәрү чыгымнарын 11 000 сум күләмендә финансларга.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә шәһәр массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында конкурслар үткәрү турында мәгълүмат урнаштырырга тәкъдим итәргә.
5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган конкурс комиссиясенә 2021 елның 30 августына кадәр конкурс нәтиҗәләренә йомгак ясарга. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләүне Зеленодольск шәһәре көнен, Васильево бистәсе көнен һәм Осиново авылы көнен бәйрәм итү кысаларында үткәрергә.

6. Зеленодольск муниципаль районыны Башкарма комитетының 2020 елның 22 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районында «Миллион чәчәк шәһәре-2020» проекты кысаларында конкурслар уздыру турындагы нигезләмәне раслау турында»1329 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына
1 нче кушымта
19.07.2021 № 1696

**«Миллион чәчәк шәһәре-2021» проекты кысаларында конкурслар үткәрү турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

Әлеге Нигезләмә 2021 елда Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм **«Яшел Үзән», «Народная газета Васильево», «Зеленодольская правда»** газеталары редакцияләре тарафыннан «Миллион чәчәк шәһәре» муниципаль проекты кысаларында конкурслар үткәрү тәртибен билгели.

Конкурста Зеленодольск муниципаль районының күп фатирлы йортларда (алга таба-КФЙ) һәм шәхси торак секторында (алга таба-ШТС) яшәүчеләр, үз территориясен төзекләндерү белән шөгыльләнүче муниципаль учреждениеләр, социаль инфраструктура объектлары (алга таба-оешмалар) һәм **«Яшел Үзән», «Народная газета Васильево», «Зеленодольская правда»** газета редакциясенә һәм Зеленодольск районының рәсми аккаунтына конкурста катнашу өчен заявка белән фотографияләр җибәрүчеләр катнаша.

Конкурста җиңүчеләр комиссия тарафыннан билгеләнә. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана. Комиссия составына массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре керә. Комиссия эшенең нәтиҗәләре компетентлы һәм ахыргы булып санала. Конкурста катнашучыларны бәяләү белән бәйле дәгъваларны Комиссия кабул итми.

Конкурсларга йомгак 30.08.2021 кадәр ясала, җиңүчеләр **Зеленодольск шәһәре көнен, Васильево бистәсе көнен һәм Осиново авылы көнен** бәйрәм иткәндә бүләкләнә.

## 2. Конкурсның бурычлары.

Конкурс Зеленодольск муниципаль районында яшәүчеләрнең йортларын һәм йорт яны территорияләрен, оешма территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту, халыкның иҗади потенциалын үстерү, аларның эшчәнлеген стимуллаштыру өлкәсендә активлыгын арттыру максатында уздырыла.

## 3. Бәйгене үткәрү тәртибе.

Конкурс барышында «Зеленодольская правда», «Яшел Үзән», «Народная газета Васильево» газеталары редакцияләренә, Зеленодольск муниципаль районы рәсми аккаунтына шәһәр һәм районда яшәүчеләрдән кергән гаризалар карала, шуннан соң җиңүчеләр билгеләнә. Конкурс материаллары (фотографияләр) комиссиягә 2021 елның 10 июленнән 20 августына кадәр җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре комиссия утырышы беркетмәсе белән

рәсмиләштерелә. Конкурста катнашу өчен заявкаларның күчермәләрен, җиңүче дип табылган палисадникларның фотосурәтләрен кушып, комиссия утырышы беркетмәсе 30.08.2021 елга кадәр Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә тапшырыла.

## 4. Конкурста җиңүчеләрне һәм лауреатларны билгеләү критерийлары:

- бизәлешнең оригинальлеге һәм матурлыгы, декоратив элементларны куллану;
- чәчәкләр һәм үсемлекләр күптөрлелеге;
- җәйнең бөтен чорында чәчәкләрнең төрлелеген булдыру максатыннан төрле вакытта чәчәк атып утырган үсемлекләр һәм чәчәкләр куллану;
- чәчәк түтәлләре урамнан яхшы күренергә, үзләренең чәчәк атулары һәм каралган булулары белән шатландырып торырга тиеш;
- чәчәк түтәлләренең эстетик төрен даими карап тору.

## 5. Конкурсларда җиңүчеләрне бүләкләү.

Җиңүчеләрне бүләкләү түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә: «Минем миллион чәчәк-2021» конкурсында - «Иң яхшы чәчәкле ишегалды» (КФЙ); «Шәһәрнең иң яхшы шәхси ишегалды» (ШТС); « Бюджет оешмасын иң яхшы бизәү» : Иң яхшы балалар бакчасы», «Иң яхшы мәктәп», «Иң яхшы социаль, мәдәни һәм ял итү оешмасы» (оешмалар). Искәрмә: «Минем миллион чәчәк-2021» конкурсында 2020 елгы җиңүчеләр «Иң яхшы чәчәкле ишегалды» номинациясендә (КФЙ) катнашмыйлар.

«Чәчәкле ишегалды-2021» бәйгесендә - «Иң яхшы ишегалды» (район җирлекләре территориясендә ШТС), иң актив җирлек башлыгы, интернет-тавыш бирү җиңүчесе, кызыксындыру бүләкләре.

«Чәчәк ат, Васильево-2021» конкурсында - «Иң яхшы чәчәкле ишегалды» (КФЙ), «Чәчәкле урам» (ШТС); « Бюджет оешмасын иң яхшы бизәү» : Иң яхшы балалар бакчасы», «Иң яхшы мәктәп», «Иң яхшы социаль, мәдәни һәм ял итү оешмасы» (оешмалар). Искәрмә: «Чәчәк ат, Васильево-2021» конкурсында 2020 елгы җиңүчеләр катнашмый.

«Чәчәк ат, Осиново-2021» конкурсында - «Иң яхшы чәчәкле ишегалды» (КФЙ), «Чәчәкле урам» (ШТС); « Бюджет оешмасын иң яхшы бизәү» : Иң яхшы балалар бакчасы», «Иң яхшы мәктәп», «Иң яхшы социаль, мәдәни һәм ял итү оешмасы» (оешмалар). Искәрмә: «Минем миллион чәчәк-2021» конкурсында 2020 елгы җиңүчеләр «Иң яхшы чәчәкле ишегалды» номинациясендә (КФЙ) катнашмыйлар.

Конкурсларга йомгак ясаганнан соң, җиңүчеләргә акчалата бүләкләр, яшел үсентенләр һәм бакча инвентаре алу өчен сертификатлар, КФЙ өчен

номинацияләрдә - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән балалар спорт мәйданчыклары тапшырыла. «Минем миллион чәчәк-2021» конкурсы кысаларында иң яхшы муниципаль учреждениегә күчмә «Екатерина Ошаринаның чәчәк кубогы» тапшырыла.

Зеленодольск муниципаль районы

Башкарма комитетының
карарына
2 нче кушымта
19.07.2021 № 1696

**«Минем миллион чәчәк-2021»**
**конкурсында номинацияләр һәм җиңүчеләрен бүләкләү**

| Номинация | Урыннар һәм бүләкләр | Сумма |
|---|---|---|
| «Иң яхшы чәчәкле ишегалды» | 1 урын-Балалар спорт мәйданчыгы | 100 000 сум |
| «Шәһәрнең иң яхшы шәхси ишегалды» | 1 урын-Иң яхшы ишегалды мәйданчыгы<br><br>2 урын-Иң яхшы ишегалды мәйданчыгы<br><br>3 урын-Иң яхшы ишегалды мәйданчыгы | 30 000 сум<br><br>20 000 сум<br><br>10 000 сум |
| «Бюджет оешмасын иң яхшы бизәү»<br><br>(балалар бакчалары, мәктәпләр, мәдәният, спорт, сәламәтлек саклау, социаль өлкә объектлары) | 1 урын-Иң яхшы мәктәп<br><br>1 урын-Иң яхшы балалар бакчасы<br><br>1 урын-Иң яхшы социаль, мәдәни һәм ял итү оешмасы | 30 000 сум<br><br>30 000 сум<br><br>30 000 сум |
| **БАРЛЫГЫ** | | **250 000 сум** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 22 июлендәге
1329 номерлы карарына
3 нче кушымта

**«Чәчәкле ишегалды-2021»**
**конкурсында номинацияләр һәм җиңүчеләрне бүләкләү**

| **Номинация** | **Урыннар һәм бүләкләр** | **Сумма** |
|---|---|---|
| Иң яхшы ишегалды мәйданчыгы » : ( район территориясендә ШТС) | 1 урын-40 000 сум<br><br>2 урын-30 000 сум<br><br>3 урын-10 000 сум | 80 000 сум |
| Иң актив җирлек Башлыгы | 1 урын | 15 000 сум |
| Интернет-тавыш бирү җиңүчесе | 1 урын | 10 000 сум |
| «Бюджет оешмасын иң яхшы бизәү»<br><br>(балалар бакчалары, мәктәпләр, мәдәният, спорт, сәламәтлек саклау, социаль өлкә объектлары) | 1 урын-Иң яхшы мәктәп<br><br>1 урын-Иң яхшы балалар бакчасы<br><br>1 урын-Иң яхшы социаль, мәдәни һәм ял оешмасы | 20 000 сум<br><br>20 000 сум<br><br>20 000 сум |
| Кызыксындыру бүләкләре | 10 приз - 5000 сум | 50 000 сум |
| **БАРЛЫГЫ** | | **215 000 сум** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына
4 нче кушымта
19.07.2021 № 1696

**«Чәчәк ат , Васильево-2021»**
**конкурсында номинацияләр һәм җиңүчеләрне бүләкләү**

| Номинация | Урыннар һәм бүләкләр | Сумма |
|---|---|---|
| «Иң яхшы чәчәкле ишегалды» (КФЙ) | 1 урын-балалар спорт мәйданчыгы | 75 000 сум |
| «Чәчәкле урам» (ШТС) | 1 урын-30 000 сум<br>2 урын-20 000 сум<br>3 урын-10 000 сум | 60 000 сум |
| "Бюджет учреждениесен иң яхшы бизәү «»<br>(балалар бакчалары, мәктәпләр, мәдәният, спорт, сәламәтлек саклау, социаль өлкә объектлары) | 1 урын-Иң яхшы мәктәп<br>1 урын-Иң яхшы балалар бакчасы<br>1 урын-Иң яхшы социаль, мәдәни һәм ял оешмасы | 20 000 сум<br>20 000 сум<br>20 000 сум |
| **БАРЛЫГЫ** | | **195 000 сум** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына
5 нче кушымта
19.07.2021 №
1696

# «Чәчәк ат, Осиново-2021»
# конкурсында номинацияләр һәм җиңүчеләрне бүләкләү

| **Номинация** | **Урыннар һәм бүләкләр** | **Сумма** |
|---|---|---|
| «Иң яхшы чәчәкле ишегалды» (КФЙ) | 1 урын-балалар спорт мәйданчыгы | 75 000 сум |
| "Чәчәкле урам» (ШТС) | 1 урын-30 000 сум<br>2 урын-20 000 сум<br>3 урын-10 000 сум | 60 000 сум |
| «Бюджет оешмасын иң яхшы бизәү»<br><br>(балалар бакчалары, мәктәпләр, мәдәният, спорт, сәламәтлек саклау, социаль өлкә объектлары) | 1 урын-Иң яхшы мәктәп<br>1 урын-Иң яхшы балалар бакчасы<br>1 урын-Иң яхшы социаль, мәдәни һәм ял оешмасы | 20 000 сум<br>20 000 сум<br>20 000 сум |
| **БАРЛЫГЫ** | | **195 000 сум** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына
6 нчы кушымта
19.07.2021 № 1696

**«Миллион чәчәк шәһәре-2021»**
**конкурсын уздыру өчен чыгымнар сметасы**

| № | Чыгымнар | Саны | Бәясе | Сумма |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Рамкада гравирланган табличка (планкетка) | 1 | 3 000 сум | 3 000 сум |
| 2 | Җиңүчеләрен бүләкләү өчен пластик сертификат А3 | 40 | 200 сум | 8 000 сум |
| **БАРЛЫГЫ** | | **11 000 сум** | | |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына
7 нче кушымта
19.07.2021 № 1696

**«Минем миллион чәчәк-2021» конкурсы комиссиясе составы**
**(Зеленодольск шәһәре)**

| № | Конкурс комиссиясе әгъзаларының Ф.И.Ат.и. | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1 | Сафонов М.В. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районының баш архитекторы |
| 2 | Ячанова Н.В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының баш агрономы |
| 3 | Завилейская И.М. | конкурс кураторы - «Татмедиа» АҖ филиалы директоры - «Яшел Үзән» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| 4 | Витовская Т.В. | «Татмедиа» АҖ филиалы директоры - «Зеленодольская правда» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| 5 | Гыйрфанов Р.А. | «Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе урынбасары |
| 6 | Чибрикова Р.Н. | конкурс кураторы - җәмәгатьчелек белән элемтә буенча белгеч |

**«Чәчәкле ишегалды-2021» конкурсы комиссиясе составы**
**(Зеленодольскмуниципаль районы җирлекләре)**

| № | Конкурс комиссиясе әгъзаларының Ф.И.Ат.и. | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1 | Завилейская И.М. | конкурс кураторы - «Татмедиа» АҖ филиалы директоры - |

| | | |
|---|---|---|
| | | «Яшел Үзән» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| 2 | Гаязова А.Р. | «Яшел Үзән» газетасының җаваплы секретаре (килешү буенча) |
| 3 | Сафонов М.В. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районының баш архитекторы |
| 4 | Ячанова Н.В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының баш агрономы |
| 5 | Чибрикова Р.Н. | конкурс кураторы - җәмәгатьчелек белән элемтә буенча белгеч |

**«Чәчәк ат, Васильево-2021» конкурсы комиссиясе составы (Васильево штп)**

| № | Конкурс комиссиясе әгъзаларының Ф.И.Ат.и. | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1 | Ячанова Н.В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының баш агрономы |
| 2 | Сафонов М.В. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районының баш архитекторы |
| 3 | Чибрикова Р.Н. | конкурс кураторы - ЗМР Советы Аппаратының массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге баш белгече |
| 4 | Матеркова Т.А. | Васильево штп ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе (килешү буенча) |
| 5 | Пушилина Е.В. | Васильево штп Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| 6 | Бабаева Р.А. | «Народная газета Васильево» басмасы мөхәррире (килешү буенча) |
| 7 | Завилейская И.М. | конкурс кураторы - «Татмедиа» АҖ филиалы директоры - «Яшел Үзән» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |

**«Чәчәк ат, Осиново-2021» конкурсы комиссиясе составы (Осиновское АҖ)**

| № | Конкурс комиссиясе әгъзаларының Ф.И.Ат.и. | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1 | Ячанова Н.В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының баш агрономы |
| 2 | Сафонов М.В. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районының баш архитекторы |
| 3 | Сәлимов А.Ю. | Осиново ав.башлыгы (килешү буенча) |
| 4 | Гыйрфанов Р.А. | «Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе урынбасары |
| 5 | Чибрикова Р.Н. | конкурс кураторы - җәмәгатьчелек белән элемтә буенча белгеч |
| 6 | Завилейская И.М. | конкурс кураторы - «Татмедиа» АҖ филиалы директоры - «Яшел Үзән» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |